Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл жирлеге составына керүче Кече Укмас авыл жирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

18 ноябрь 2022 ел № 2

Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл жирлеге составына керүче Кече Укмас авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Кече Укмас авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан,1 нче төркем инвалидлардан һәм өлешчә мобилизацияләүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы жирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;
- торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру );
- авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу );
- авыл җирлеге территориясен жәйге вакытта чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәткеавыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Бәтке авылы,Ленин урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы,23 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы: Ф.М.Динмөхәмәтов

СОВЕТ БЕТЬКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000186 БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ